РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ
ЧЕРЕМШАНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
ул. Советская, д.32, село Черемшан, 423100

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
Совет урамы, 32е йорт, Чирмешән авылы, 423100

тел./факс +7(84396) 2-59-00, email: cheremshan@tatar.ru, http://cheremshan.tatarstan.ru

02.11.2021 ел №71

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы Советы
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының муниципаль милкен хосусыйлаштыру тәртибе турында» 2017 елның 13 декабрендәге 132 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

«Дәүләт һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 2 июлендәге 352-ФЗ номерлы Федераль законнары, Татарстан Республикасының «Чирмешән муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасының Чирмешән муниципаль районы Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советының 2017 елның 13 декабрендә кабул ителгән 132 номерлы «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы муниципаль милкен хосусыйлаштыру тәртибе турында» карары белән расланган (район Советының 2014 елның 24 апрелендәге 152 номерлы карары белән кертелгән үзгәреш белән) Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы муниципаль милкен хосусыйлаштыру тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. 5 бүлекнең 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «3. Муниципаль милекне хосусыйлаштыруның прогноз планына (программасына) кертелгән унитар предприятиеләр, акционер җәмгыятьләр һәм җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятьләр Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасына» бухгалтерлык исәбе турында Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән аның мәҗбүри нөсхәсен бирү өчен срокта еллык

бухгалтерлык (финанс) хисабын тапшыралар, әгәр күрсәтелгән предприятиеләр һәм җәмгыятьләр «Бухгалтерлык исәбе турында» 2011 елның 6 декабрендәге 402-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясында (алга таба - бухгалтерлык (финанс) хисаплылыгының дәүләт мәгълүмат ресурсы) каралган бухгалтерлык (финанс) хисаплылыгының дәүләт мәгълүмат ресурсын формалаштыру максатларында мондый хисапны, шулай ук квартал, ярты ел, тугыз ай өчен арадаш бухгалтерлык (финанс) хисаплылыгын бирү вазыйфасыннан азат булсалар - хисап чоры тәмамланганнан соң утыз көннән дә соңга калмыйча, күрсәтелгән хисапта булган мәгълүматны Чирмешән муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча урнаштыру белән: http://cheremshan.tatarstan.ru

Бухгалтерлык (финанс) хисаплылыгының дәүләт мәгълүмати ресурсын формалаштыру максатларында әлеге предприятиеләр һәм җәмгыятьләр еллык бухгалтерлык (финанс) хисаплылыгын тапшырса, башкарма хакимиятнең вәкаләтле федераль органы, Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимияте органы, җирле үзидарә органы мондый хисапны ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасын кулланып ала»;

1.2. 11 бүлекнең 8 абзацында «бухгалтерлык балансы, керем һәм чыгымнар счетлары» сүзләрен «еллык бухгалтерлык (финанс) хисабы» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Советының икътисад сәясәте, бюджет һәм җирле үзидарә, Совет регламенты, хокук тәртибе, экология һәм халык куркынычсызлыгы буенча даими комиссияләренә йөкләргә.

Муниципаль район башлыгы,
Совет рәисе Ф.М. Дәүләтшин